Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2019 нчы елның 25 нче октябре 264№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советының 2013 нче елның 30 нчы гыйнварындагы
10 номерлы “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Советы Регламенты турында" карарына
үзгәрешләр кертү турында

Әлки районы прокурорының 2013 нче елның 30 гыйнварендәге 10 номерлы карарга протесты нигезендә һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә турындагы законнарына үзгәрешләр кертү, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары карарларына коррупция күренешләре өчен шартлар тудыруга ярдәм итүче нигезләмәләрне кертүгә юнәлдерелгән закон актлары кабул итү белән бәйле рәвештә, шулай ук "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 8 өлешенең 11 пункты нигезендә мондый нигезләмәләрне ачыклау һәм бетерү, үз эшчәнлегенең оештыру һәм процедура мәсьәләләрен җайга салу максатларында, Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2013 нче елның 30 нчы гыйнварындагы 10 номерлы “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы Регламенты турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 4 статьяның 2 пунктында “катнашырга” сүзеннән соң “прокуратура органы вәкилләре” сүзләрен өстәргә;
- 4 статьяның 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Советның ачык утырышларында иҗтимагый оешмалар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары вәкилләре, гражданнар катнаша ала”;

- 10 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Карар проектлары, сессияне үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча, район прокурорына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җибәрелә”.

2.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстембә калдырам.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы Никошин А.Ф.